| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.06.2023 № 158/БК-к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен
карау регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 26.01.2023елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Буа район башкарма комитетында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 24 декабрендәге 614-п номерлы карары белән расланган (ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 апрелендәге 116Бк/к карары, 04.10.2018 № 304Бк/к, 31.07.2019 № 328Бк/к карары редакциясендә) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. VII бүлектә:

7.4.2 пунктын үзгәртергә һәм киләсе редакциядз бәян итәргә:

«7.4.2. Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Рәисе мөрәҗәгатьләрен карау буенча йөкләмәләрнең үтәлеше аерым контрольгә куела, 15 көнгә кадәр карала.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Л.Р. Шакирҗанов